# **Әдәпленең – көлмәге сәдәпле**.

*Кеше холкын күзәт, узеңнекен төзәт*!

Максат: 1. Укучыларда әдәплелек тәрбияләү.
2. Узара аралашу кагыйдәләрен ойрәнү.
3. Укучыларның уз фикерләрен эйтеп бирү күнекмәләрен үстерү.

Буген безнең энгәмәбез эдәплелек, матур сөйләшү турында барачак.
- Укучылар эйтегез әле, әдәпле кеше нинди була?
- Ни очен безгә әдәпле булырга кирәк? (Укучыларның фикерләре)
Халкыбызда да әдәплелеккә карата торле мәкальләр бар:
" Май чулмәге тышыннан билгеле."
"Киеменә карап каршы алырлар, акылына карап озатырлар."
Кешеләр белән аралашканда, алар синең нинди булуыңа карап фикер йортәләр, аңа шундый карашта булалар.
- Укучылар, әдәплелек кагыйдәләрен беләсезме соң?
Телефоннан сөйләшү" уены уткәрелә. ( 2 укучы , берсе әдәпле итеп, э икенчесе әдәпсез итеп сойләшә) укучылар үзлэренең фикерләрен әйтәләр.
-Әдәпле кеше әле ул матур итеп исәнлэшэ белергэ дэ тиеш. Э сез исәнләшү кагыйдәләрен беләсезме соң? ( төрле очракларда бер-береңә сәлам бирү кагыйдәләре укыла).
-Әдәплелекнең бер билгесе- ул матур сүзләр белән кешегә мөрәҗәгать итү. "Татлы сүз- җан азыгы" – дип борынгылар юкка гына әйтмәгәннәрдер.
Әйдәгез әле укучылар, сезнең белән тагын бер уен уйнап алыйк.
Менә сезгә алма, аңа купме шырпы кадалган. Безнең дә йөрәгебезгә кайвакытта "шырпылар" кадалган була – кэефсез , авыр вакытларыбыз була. Кемнеңдер жылы сүзеннән бу авырлыклар эреп юкка чыгалар. Сез дә һәрберегез шушы алмадагы шырпыны алыгыз һэм бер – берегезгә матур сүз әйтегез. (Укучылар бер-берсенә матур сүзләр әйтәләр).
-Укучылар, күрәсезме, ягымлы сүздән алмада шырпылар калмады, ләкин шырпы кадалган эзләр бетмәде. Безнең күңелләрдә дә шулай, авыр сүзнең эзен тиз генә бетереп булмый.
-Төрле ситуацияләрдә үз-үзегезне тоту кагыйдәләрен дә искә төшереп китик әле. Укучылар, бу ситуацияләрдә үз-үзегезне ничек тотар идегез? ( укучылар текстлар укыйлар һәм фикерләрен әйтәләр):

1. *Мәктәп коридорында бер төркем укытучылар сөйләшеп тора. Класс җитәкчесен күреп алдым да: " Исәнмесез, Галия апа" , - дип узып киттем. Мин дөрес эшләдемме?*
2. *Сумка тоткан, башында бүреген кырын салган малай сагыз чәйни-чәйни юлдан бара. Янәшәдә генә ике кулына да авыр сумка тоткан әби атлый. Малай әбигә игьтибар итми генә узып китте. Малайның ялгышы нәрсәдә?*
3. *Укучы өстәл янында рәсем ясый. Шулчак әбисе:" Балам, күзлегемне табарга булыш үле", - диде. Бала: " әнә бит, күзлегең шкаф өстендә бит, дип эйтте һәм эшен дәвам итте. Бала дөрес әшләдеме?*
4. *Юлдан бер бабай атлый, кулында биш төргәге бар. Янәшәдән бер малай бара. Шулчак ул: " Бабай, әнә бер төргәгегез төшеп калды бит" – диде. Бабай: " Юк бит, барысы да үземдә,-диде. Ә малай: " Кулыгызда биш төргәк иде бит, дүртесе*

*генә бит әнә,”-диде дә китеп барды. Бабай:” И улым, сине математикага яхшы өйрәткәннәр икән, тик ... бер кагыйдәне белмисең икән” – диде. Малай нинди кагыйдәне белми?.*

- Кеше әдәпле булып туамы, әллә үсү нәтиҗәсендә әдәплелеккә өйрәнәме?

(Укучыларның җавабы)

- Сез әле яшь, узегездә күп кенә гадәтләрне бетереп, икенчеләрен тәрбияли аласыз. Яшь вакытта алган тәрбия гомер буена житэә тик яхшы гадәтләргә өйрәнергә бер вакытта да соң түгеллеген онытмагыз. ( Хикәя укыла):

“*Әнисе үзенең улы начарлык эшләгән саен, рәшәткәгә бер кадак кага.Еллар уза, бала үсеп буйга житә, армиягә барып кайта. Бер көнне ул кадакларга игътибар итә һәм әнисе янына килә. “Әни, нигә син шулкадәр күп кадак кактың?- дип сорый .*

*Әнисе:” Улым, менә син бер начарлык эшләгән саен, мин бер кадак кага бардым. Курәсеңме, ничаклы алар?”- ди. Улы уйга кала һәм гел яхшылыклар эшләргә сүз бирә. Шулай эшли дә. Менә ананың улы да олыгая, әнисе исә картая. Улы әнисе янына бер көнне килә дә:” Әни, кара әле, рәшәткәдә бер кадак та калмады. Мин , яхшылык эшләгән саен, берсен ала бардым. Начарлыгыма каршы яхшылык эшләдем, - ди. ә әнисе болай ди:” Улым , әйе син күп яхшылык эшләдең һәм, шулай итеп, начарлыкларыңны бетердең дә кебек, тик әнә, кара әле рәшәткәләргә, никадәр кадак эзе. Аларның эзе калган бит” – ди.*

Укучылар начарлыкны төзәтергә бер кайчан да соң түгел дигән фикергә киләләр:

“Әгәрдә сез, нинди дэ булса начарлык эшләсәгез аны төзэтергә тырышыгыз һәм гафу үтенэ белегез.”

Тагын бер хикәя укыла һәм укучылар үзләренең фикерләрен әйтәләр.

“*Павлик мәктәпкә пошаманга төшеп килде. Өйдә бик озак утырса да, мәсьәләне чишә алмады. Хэзер малайга “ мәсьәләне кемнэн күчерергә?” – дигән сорау тынгылык бирмәде.*

*Сыйныф бүлмәсе ишеген Зина ачты. Ул мәсьәләне чишкән.*

- *Зина, мәсьәләдә ничә гамәл бар?*
- *Өч, - диде кыз, - ә син мәсьәләне чишмәдеңмени?*
- *Минем чыкмады. Бир әле, Зина , тиз генә күчереп алыйм .*
- *Эх, Павлик, ни өчен узен уйларга теләмисең? – диде Зина, уфтанып, һәм малайга дәфтәрен сузды.*

*Павлик беренче, икенче гамәлне кучерде һәм өченчесенэ күчте. Менэ шунда Зинанын хата жибэргәнен сизде: 23 дип язасы урынга кыз 32 дип язган. Үз дәфтәрендә Павлик санны дөрес язды, әммэ Зинаның хатасын төзәтмәде.*

*Укытучы укучыларның дәфтәрләрен тикшерергә җыеп алды. Һәм икенче көнне болай диде:*

- *Павликка “5” ле, булдырган, мәсьәләне дөрес чишкән. Синең, Зина, “4” ле, хата җибәргәнсең.*

*Зина, гаҗәпләнеп, Павликка күз ташлады, тегесе кызаруыннан башын түбән игән иде ...”*

*(Фикерләр тыңлана).*

-Укучылар , шуның белэн әзерләнгән класс сәгатебез тәмам. Бүгенге сөйләшү һәрберегезнең куңелендә озак сакланыр һәм сез алардан үзегезгә нәтиҗә ясарсыз дип ышанабыз.

# Тема: Дуслык

Максат: Дуслык турында фикер алышырга өйрәтү.
Дуслыкны саклый белергә, дус була белергә өйрәтү.
Дуслыкның иң мөһим сыйфатларның берсе булуына ышаныч тәрбияләү.
Материал: Гәрәева Г.Х. «Уртаклашыр тәҗрибәм бар”, www.бала.рф
http://mon.tatarstan.ru/
Рөстәм Мингалим “Дусларың гына булсын”.
Татар халык уены»Куш кулым»

Җиһазлау: ноутбук, прекцион аппарат, презентация, әкият
геройлары рәсемнәре, мәсьәләләр һәм мәкальләр язылган
карточкалар, фломастерлар,
альбом битләре, кулланмалар .

Дәрес барышы
I.МОЭ
1) Исәнләшү, танышу;
2) Уңай- психологик халәт тудыру;
3) Уку мәсьәләсен кую.

Укучылар, мин сезгә бер әкият сөйлим. Дәрестә нәрсә турында сөйләшүебезне шуннан аңларсыз.
Борын- борын заманда, биек тауда, гаиләсе белән көтүче яшәгән. Ул бик ярлы булган. Бер төнне аларның ишеген 3 кеше шакыган. Көтүченең өе бик кечкенә икән. Ул аларга : «Берегез генә керегез, өем бик кечкенә минем,-дигән һәм: «Сез кемнәр соң?»- дип сораган.
-Без – Дуслык, Бәхет, Байлык. Син кайсыбызны чакырасың, шул керер ,-дигәннәр алар.
Сезгә сорау:
-Көтүче өенә кемне чакырган? (Укучыларның җавабын тыңлау)
-Төркемнәрдә киңәшегез.

_Димәк, бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез?
(Дуслык турында)

II. Уку мәсьәләсен чишү.

1. –Ә нәрсә соң ул дуслык һәм аның нинди төрләре бар? Бу сорауга җавап эзләү өчен без сезнең белән Стё зе класс структурасын кулланырбыз. Моның өчен һәркем алдында торган битне ала һәм үзенең фикерләрен яза. Шуннан соң сызык сыза, минем команда белән урыннардан торып, һәркем үзенә пар эзли, үзендә булмаган фикерләрне өсти. Сезнең бурыч: күбрәк кеше белән аралашып, күп фикер туплау.
Урыннарга утырабыз.Фикерләрне тыңлыйбыз.
*(Дус синең өчен шатлана, борчыла, хәлеңгә керә, ярдәм итә, кирәк вакытта аңлата, дөресен әйтә, син аңа ышанасың, сереңне сөйлисең, ....)*
-Әйе, укучылар, нинди матур сүз. Дус – ул сиңа һәрвакытта да ярдәмгә килүче әниең, әтиең. Дус – ул яраткан китабың, аны укыган саен укыйсы килә. Дус – ул

сине белем иленеӊ серләренә төшендерүче укытучыӊ. Дус – ул колаклары өзелгән, сиӊа авыр вакытта зарыӊны тыӊлаучы яраткан йомшак уенчыгыӊ. Дуслык – ул бик кыйммәтле язмыш бүләге. Дуслык безгә укырга, эшләргә, яшәргә ярдәм итә. Ул безне әйбәтрәк, яхшырак, көчлерәк итә. Кешегә дусларсыз яшәү мөмкин түгел. Дустыӊ булу – зур байлык.

2. Аӊлатмалы сүзлектән Дус сүзенә билгеләмәне тыӊлап үтәбез.

ДУС:

1. Берәүгә карата дуслык мөнәсәбәтендәге кеше, якын иптәш;
2. Яраткан кеше;
3. Берәүне яклаучы, аныӊ белән фикердәш, теләктәш, аныӊ яклы кеше;

3. Ситуацияләр.
   Дус һәм дуслыкныӊ ни икәнен белдек. Ә хәзер дусларныӊ нинди булуы турында белү өчен Инсайд-Аутсайд Сёкл структурасын кулланырбыз.
   Урыннардан торып парлашабыз. Каршыдагы иптәшеӊ белән дуслашасыӊ. Түгәрәккә урнашасыз. Эчке һәм тышкы түгәрәк хасил итәсез. Сезгә шундый ситуация укып китәм.Сез бу очракта нишләрсез?

   1.ситуация. Синеӊ дустыӊ өй эшен хәзерләп килмәгән, күчерергә сорап тора. Син нишлисеӊ? (Уйлый 30 с., Башта берсе, аннан икенчесе сөйли 30 с) Парына рәхмәтәйтеп саубуллаша. 5 адым атлый, икенче пар таба)
   2. ситуация.Синеӊ дустыӊ сөйләшкәндә начар сүзләр куллана. Син нишлисеӊ?
   3ситуация.Синеӊ дустыӊ начаррак укый башлады, чирегенә дә “3”ле билгеләре чыга. Сиӊа аныӊ белән уйнамаска да кушалар. Син нишләрсеӊ бу очракта?
4. һәркемгә аерым сорау: Иӊ якын дустыгыз кем һәм ни өчен нәкъ менә аны дустыгыз итеп сайладыгыз? (Берничә укучыдан сорау)
5. Дус һәм дуслык турында сөйләшүләрдән чыгып, дуслык турында белгәннәрне барлыйбыз. Модель Фрейер структурасын кулланырбыз.
   Һәркем алдында торган бер бит кәгазьне урталай, аннан тагын урталай бөкли. Уртадан өчпочмак ясап бөкли. Кәгазьне ача. Уртага дуслык дип яза. Һәм үзеӊмисалларын яза.

6. Укучылар, дуслык турында бик күп сөйләргә мөмкин. Өстәлдәге чыбыкларга игътибар иттек. 1 нче номерлар чыбыкны ала, сындырып карый. Ничек сынды? Ә хәзер шундый берничә чыбыкны бергә сындырып карагыз. Бу эш җиӊел булдымы?
7. Димәк шуны белегез: дуслык ул бердәм булганда гына көчле икән.
   Инде сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: Дус булу- җиӊел эш түгел, ә аны саклап калу- тагын да авыррак. Бүгенге дәрестә сөйләшкән сүзләр киләчәктә сезгә ярдәм итсен иде. Алдыгызда торган йөрәкләрне рәхмәт әйтеп, дустыгызга бирегез.

1 конкурс. Уйнаучы әти-әниләргә өй эше итеп бирелгән конкурс.. (Гаиләләр үзләре белән таныштыралар. Бүләк жыр ,бию, шигырь башкаралар.)(1-5 балл)

2 конкурс. Разминка. Мин бер хикәя укыйм. Тиз укыйм. Игътибар белән тыӊлагыз.

АЛМА АГАЧТА ҮСӘ. УЛ ЯШЕЛ ДӘ, КЫЗЫЛ ДА, САРЫ ДА БУЛА. КЫЗЫЛ, САРЫ АЛМА БАЛЛЫ, Ә ЯШЕЛ АЛМА АЧЫ. КӘБЕСТӘ БАКЧАДА ҮСӘ. АЛМАДАН ВАРЕНЬЕ КАЙНАТАЛАР. АНЫ КИПТЕРЕРГӘ ДӘ БУЛА. МИНЕМ ӘНИ БИК ТӘМЛЕ АЛМА БӘЛЕШЕ ПЕШЕРӘ.
-Бу хикәядә кайсы җөмлә артык?
(Кәбестә бакчада үсә.) (Дөрес җавап бирүче гаиләгә 1балл бирелә)

3 конкурс. Нәрсә кебек? ( Укытучы укып бара, командалар дөрес җавапны әйтеп баралар.) Кошлар,хайваннар белән чагыштыру:
хәйләкәр(төлке кебек), кире(ишәк), такылдык(үрдәк), тугры(эт), куркак(куян), ерткыч(бүре), көчле(фил), ялагай(песи).(1балл)

4 конкурс. Малайлар исемнәрен- кызлар,кызлар исемнәрен малайлар исемнәренә әйләндерергә. Мәсәлән: ЗӘКИ-ЗӘКИЯ, МӨНИРӘ-МӨНИР.
(Наил, Гали,Раил, Әдил; Илнара, Дамирә,Фәридә, Илгизә,Вәсимә.) (Жюри тикшерә, бер дөрес сүзгә-1балл)

Музыкаль пауза.

5 конкурс. “Ике төрле бер сүз”уены. Сүзләр төрле, ә мәгънәләре бер(синонимнар).Мәсәлән,былбыл-сандугач, өлгер-җитез.
Песи-мәче, әшәке-начар, азык-ашамлык, тату-дус, бәби-бала, сөлге-тастымал, матур-чибәр, кызу-эссе, түгәрәк-йомры, ирек-азатлык.(1 балл)

Командалар биремнәрне эшләгәнче, уйнаучы балалар өй эше итеп бирелгән шигырьләрне яттан сөйлиләр. ( Шигырьләр дидактик материаллар бүлегендә язылган.)
Конкурс җавапларын тикшерү.

6 конкурс. “Уртасын тап!” уены. Уйнаучы әти-әниләр өчен бирем.( 1 балл)
- Ак та түгел, кара да түгел.Нинди?(соры)
- Кыш та түгел, җәй дә түгел. Нәрсә?(көз)
- Кайнар да түгел, салкын да түгел. Нинди?(җылы)
- Яхшы да түгел, начар да түгел. Нинди?(уртача)
- Коры да түгел, юеш тә түгел. Нинди?(дымлы)
- Иртә дә түгел, кич тә түгел. Нәрсә?(Көн)
- Матур да түгел, ямьсез дә түгел. Нинди?(сөйкемле)

7 конкурс.( 1 слайд)Бу бирем – барлык командаларга да. Мин мисал китерәм, ә сез нинди жанр икәнен әйтерсез: бу әкиятме, мәзәкме, бишек җырымы, такмакмы, табышмакмы, мәкальме? (1балл)
1. Ата-ананы тыңлаган адәм булган,
Тыңламаган әрәм булган. (Мәкаль)

2. Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка җиләккә,
Рәисәгә бүләккә. (Бишек җыры)

2. Борын-борын заманда яшәгән, ди, карт белән карчык. Аларның ике кызы булган. Олы кызлары усал да, ялкау да, саран да икән. Шуның өчен аны беркем дә яратмаган. Кече кыз үги булган. Үзе уңган, үзе ягымлы икән. Аңа кешеләр сокланып туя алмаганнар...(әкият)
3. Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр кыярлар.
Борыныңны бик күтәрмә,
Чиләк элеп куярлар. (такмак)
5. Кайвакыт ул йомшак мамык кебек,
Кайвакытта юләр тавык кебек,
Кайвакытта үткен кылыч кебек,
Кайвакытта зәһәр борыч кебек,
Кайвакытта ачы балан кебек,
Кайвакытта чага елан кебек.
Ул нәрсә? (Тел)
6.Исламның ертылып беткән, пычрак бүреген күргәч, әнисе “аһ” итте.
-Нәрсә булды?-дип сорады ул.
-Шул иптәш малайлар инде. Баштан бүрекне салдырып алдылар да аның белән футбол уйнарга тотындылар.
-Ә син кайда булдың соң?
-Капкада тордым. (Мәзәк)
(Сигнал карточкалар белән күрсәтү.)

Уен. “Дөрес сайла!” (2слайд) (Дөрес җавап туры килгән сан кадәрле кулны чәбәклибез)
Югач кулларны сөртәбез:1. сөлге, 2.кулъяулык, 3.күлмәк белән.
Өстәлгә җәябез: 1.җәймә, 2.газета,3. ашъяулык.
Ашарга утыргач әйтәбез:1. “Тыныч йокы!”, 2.“Ашыгыз тәмле булсын!”, 3.“Рәхим итегез!”
Макаронны ашыйбыз: 1.кул, 2. калак, 3.чәнечке.
Ашап туйгач әйтәбез:1. “Тәмсез булды!”,2. “Рәхмәт, тәмле булды!”,3. “Аз булды!”

8 конкурс. ( 3 слайд) Башваткыч-баш эшләткеч.
Гөлсем апаның Дилә исемле кызы, Линар исемле улы, Акбаш исемле сыеры, Сарбай исемле эте, Йомгак исемле песие бар. Гөлсем апаның ничә баласы бар?
Музыкаль пауза.
А.б. Тапкырларга,зирәкләргә
Бездә урын гел түрдән.
Кайда? Нәрсә? Кайчан була?
Әйтеп бирсен шуны белгән.
Я, дусларым, игътибар!
Тапкырлар һәм зирәклардән
Дөрес җавап көтәбез.

9 конкурс. Супер-табышмаклар.
Ни өчен супер? Чөнки аларның җаваплары бер генә түгел, берничә.
1. Тешләре бар, авызы юк...(Тарак, пычкы, тырма)

2. Бөтен кешене ашата, ә үзе ашамый. (Калак, кашык, чәнечке)
3. Тегеп булмый бернәрсә дә, энәләре күп булса да. (Керпе, нарат, чыршы)
4. Яза белә, ә укый белми. (Ручка, карандаш, акбур)
5. Аяклары булмаса да, көне-төне йөгерә.(Су, сәгать)
6. Тавышы нык, дөньяны яңгырата,
Безне иртән йокыдан уята. (Әтәч, быргы, будильник)
7. Ачыла да ябыла, җавабы тиз табыла. (Ишек, тәрәзә, күз, авыз)
8. Икесе дә вак, икесе дә ак.
Аерыйм дисәң, авызыңа кап! (Шикәр, тоз)
9. Үзе кабыклы, үзе бик ачы, үзе файдалы. (Суган, сарымсак, лимон)

10 конкурс. (4слайд)Сүзләр эчендә нинди саннар һәм төсләр бар?
ӘфлисУН, САРЫк.
Бердәмлек, кузгалак, балачак, сикерү, күкерт, төчкерү, каралты, сигезаяк, карак, кызыллык, яшелчә, йөзек, балдак, фикер, карама, бишек, себерке,гармун.
( Сигнал карточкалар белән күрсәтәләр)

Уен. “Әйе, юк”. ( Әйе-тыныч кына утырабыз, юк- аяклар белән идәнгә тибү хәрәкәтләре ясыйбыз.)
Тиз генә җавап бирергә.

- Ашар алдыннан кулларны юарга кирәк. (Әйе)
- Җәй артыннан кыш килә.(Юк)
- Куянның колаклары кыска, койрыгы озын. (Юк)
- Китап- кешенең дусты.(Әйе)
- Татарлар ике куллап исәнләшәләр. (Әйе)
- Әтәч йомырка сала. (Юк)
- Боз кардан тизрәк эри. (Юк)

Уйнаучыларга да, тамашачыларга да бирем.
Милли ашамлыкларны кем күбрәк белә? (Баллы призтарату.)

(Жюри әгъзалары бәйрәмгә нәтиҗә ясый, урыннар билгели. Җиңүчеләрне атый. Гаиләләргә “Иң зыялы гаилә”, “Иң күркәм гаилә”, “Иң тырыш гаилә” номинацияләре бирелә.)

А.б. Йокысыннан тора кояш
Елмаеп көлеп кенә
Болыт арасына да ул
Елмаеп килеп керә.
Шушы кояштай тормышның
Кадерен белеп кенә,
Әйдәгез бер яшик әле,
Елмаеп – көлеп кенә.

Ә хәзер барыгызны да биюгә чакырабыз.
(Татар бию көе)

Ук. Бәйрәмебез ахырына якынлашты.Рәхмәт сезгә. Барыгызга да гаилә бәхете, тыныч һәм имин тормыш, якты өметләр телибез. Сау булыгыз!

**Внеклассное занятие: Знакомство с культурой татарского народа.**

2 класс русскоязычная татарская группа

Цель: Ознакомление детей с особенностями **татарской национальной культуры**.

Задачи:

1. Познакомить детей **с культурой татарского народа**.
2. Знакомить **с татарскими** национальными костюмами, особенностями орнамента, праздниками, национальной кухней.
3. Расширять словарный запас с помощью **знакомства с новыми словами**, обозначающими **татарскую национальную одежду**: камзул, калфак, тюбетейка, кыстыбый, чак-чак.
4. Обогащать музыкальный опыт детей, посредством пения **татарской песни «Апипа»**.
5. Воспитывать интерес к **татарской национальной культуре**.

Материал: Слайды с изображением **татарских** национальных костюмов, запись **татарской песни «Апипа» в исполнении Рената Ибрагимова**, тюбитейка, инвентарь для игр «Перетягивание каната», раскраски тюбитейки.

Ход занятия:

Организационный момент:

Здравствуйте! Исэнмесез!(на доске запись прикрепляется)

Ребята, вижу вы готовы к уроку! Сегодня он необычный. К нам пришли гости. У нас праздник, давайте поприветствуем всех!

Я думаю урок у нас получится познавательным и интересным. А для этого нужно быть внимательным и старательным.

**Дети читают наизусть.**

В.Степанов

1 ученик Сколько нас, нерусских у России,
И татарских, и иных кровей.
Имена носящих не простые,
Но простых российских сыновей!
Любим мы края свои родные
И вовек – ни завтра, ни сейчас.
Отделить нельзя нас от России.
Родина немыслима без нас.

2 ученик: Я русский человек, и русская природа
Близка мне, я ее пою
Я русский человек, сын своего народа
Я с гордостью гляжу на Родину свою.

3ученик: В годину бед она всегда бывала
Единой, несгибаемой, стальной
Врагу навстречу Русь моя вставала
Одною дружной, грозною стеной.

4ученик: И по призыву Дмитрия Донского,
По зову Минина она шагала в бой,

Не зная страха, гордо и сурово
Вздымая знамя славы над собой.

Учитель:

**-Ребята, о чем это стихотворение?**

*(Ответы и рассуждения детей.)*

-Много народов проживают в России, всем в нашей стране хватит места. Каждый народ интересен и имеет свою многовековую историю. Ребята, а какие национальности проживают в нашей Республике Башкортостан?

Дети:
-Русские, татары, башкиры, мордва, чуваши, украинцы.
Учитель:
-Ребята сегодня мы с вами **познакомимся с культурой татарского народа**. **(СЛАЙД 1)** У нас в классе тоже есть ученики этой национальности. Вы все вместе находите общий язык: играете, общаетесь, ходите в школу. **Татарский** народ тоже имеет свою **культуру**, праздники, обычаи и традиции, которые помнит и чтит. **(НА ДОСКЕ КАРТИНКИ)**

Каждый народ богат своими традициями, обычаями, и нравами. Есть такая пословица:
**"Народ, не знающий своего прошлого, не имеет будущего ". (НА ДОСКЕ ПРИКРЕПЛЯЮ ПОСЛОВИЦУ).** Как понимаете смысл этой пословицы?

***Рисунки дерева (растущее и завявшее) на доске.***
Чем отличаются эти деревья?
Почему одно дерево может расти, а другое нет?
С кем можно сравнивать эти деревья?
Не зная свои корни, прошлое, у народа нет будущего.
**ПОКАЗ ШЭЖЭРЭ.КАК ПОНИМАЕТЕ ЭТО СЛОВО?**
**РОД, РОДОСЛОВНАЯ, НАШИ КОРНИ КАК И У ДЕРЕВА.**

Если в каких-то районах нашей республики забыты традиции; то в других районах наш быт проникает почти забытые обряды и праздники в этом помогают прадедушки, прабабушки, которые сумели сохранить всю изюминку, настоящий глубокий смысл татарского народа, жить в согласии, в мире, передавать свое ремесло молодому поколению, и в то же время уметь находить время для праздников, для игр зимой в домах, летом на бескрайних лужайках.
Татарский костюм **СЛАЙД 2** представляет собой уникальную систему народного художественного творчества, включавшую в себя богато орнаментированных головных уборов, Все элементы системы выступали согласованно, сочетаясь друг с другом по форме, цвету, материалу изготовления, образуя единый стилевой ансамбль. Женские камзолы шили из цветного, чаще однотонного бархата и украшали по бортам и низу
тесьмой, мехом. **СЛАЙД 3**

Поверх камзола мужчины носили длинный просторный халат (жилэн) с небольшим шалевым воротником. **СЛАЙД 4**
В холодное время года носили бешметы, чикмени, крытые либо дублёные шубы. Головным убором мужчин, как уже упоминалось, была четырёхклинная, формы тюбетейка (тубэтэй) **СЛАЙД 5; НА ДОСКЕ ВЫВЕШИВАЮ НАДПИСЬ (ТЮБЭТЭЙ)** или в виде усечённого конуса (кэлэпуш).
Праздничная бархатная позументная тюбетейка вышивалась, гладьевой вышивкой **(ПОКАЗ ГЛАДЬЕВОЙ ВЫШИВКОЙ НА СТАРИННОЙ СКАТЕРТИ).**

Девушки носили мягкие белые калфаки, тканые или вязаные. Замужние женщины поверх них, выходя из дома, набрасывали легкие покрывала, шелковые шали, платки. **КАРТИНКА НА ДОСКЕ**
Татарки плотно повязывали голову, надвинув платок глубоко на лоб и завязав концы на затылке – так его носят и сейчас

Праздничные женские башмачки были орнаментированы в стиле многоцветной кожаной мозаики.**СЛАЙД 6.** Рабочей обувью служили лапти татарского образца (татар чабата): с прямоплетёной головкой и низкими бортиками. Их надевали с белыми суконными чулками (тула оек).

Для одежды татар характерен традиционный трапециевидный силуэт с «восточной» насыщенностью цветов, обилие вышивок, применение большого количества украшений.

У каждого народа есть свои национальные праздники. Многие из этих праздников родились ещё в древности или даже тысячу лет назад. Всё вокруг: деревни и города, вещи, одежда, профессии, природа меняются, а народные праздники продолжают жить.Потому что праздники — это сердца, души народа. Татарские народные праздники восхищают чувством благодарности и почтения людей к природе, к обычаям предков, друг к другу. Русское слово "праздник" происходит от древнерусского порозденъ, то есть порожний. Получается, что праздник — это время пустое, не занятое, то есть свободное от труда и других обычных занятий. Девушки и молодые люди танцевали под баян, было слышно с одного конца деревни в другую.

***ВИДЕО- ТАТАРСКИЙ ТАНЕЦ ТАНЦУЕТ УЧЕНИЦА.***

**Пели татарские народные «длинные песни», длинные потому что тянулись слова, это не каждый мог петь, с восхищением , с уважением слушали собравшийся народ.**

**Разучивание татарской народной песни «Эпипэ»**
Знакомство с национальной музыкой, прослушивание аудиозаписи с татарской музыкой.
Цель: учить детей определять национальные особенности музыки, закреплять умение наблюдать, сравнивать, анализировать, делать выводы.

***ПЕСНЯ АПИПА (*прослушивание Рената Ибрагимова.**
**С каким настроением поет артист песню?**
**Перевод песни читаем с детьми?**
**Понравилась ли вам песня?**

**А чем она понравилась?**

**Разучивание песни, на партах розданы текст песни детям).**

У татар же есть два слова, означающие праздник. **Религиозные мусульманские праздники называются словом гает (ает) (Ураза гаете — праздник поста и Курбан гаете — праздник жертвы).** А все народные, не религиозные праздники по-татарски называются бэйрэм.
Раньше он праздновался перед началом весенних полевых работ, в апреле, сейчас **сабантуй (РИСУНОК НА ДОСКЕ ПРИКРЕПЛЯЮ)** устраивают в июне – по окончании сева. Раньше к сабантую готовились долго и тщательно – девушки ткали, шили, вышивали национальным узором платки, полотенца, рубашки; каждой хотелось, чтобы, именно ее творение стало наградой самому сильному джигиту - победителю в национальной борьбе или в скачках. А желающие жители деревни ходили по домам и собирали подарки, пели песни, шутили. Подарки привязывали к длинному шесту.
На время сабантуя избирался совет из уважаемых аксакалов (пожилые люди),они назначали жюри для награждения победителей, следили за порядком во время состязаний. Сабантуй начинается с самого утра. Женщины надевают свои самые красивые украшения, в гривы лошадей вплетают ленточки, подвешивают к дуге колокольчики. Все наряжаются и собираются на майдане – большом лугу. Развлечений на сабантуе великое множество.

Главное - это, конечно же, национальная борьба курэш. Обычно недели за две до сабантуя претенденты на победу в этом состязании переставали выходить на полевые работы и ели сколько душе угодно свежих яиц, масла, меда, набирались сил, чтобы защищать честь родной деревни. Для победы в курэш требуется немало силы, хитрости и ловкости. Победитель курэша – абсолютный батыр - получает в награду живого барана и с ним на плечах совершает круг почета. **СЛАЙД 7**

**"Народные праздники татар".**

Цель: Формирование у детей представления о богатой народной культуре татарского народа, знакомство с этнографией и фольклором татар.

Задачи:
- Продолжать знакомить детей с традициями и обычаями татарского народа.
- Формировать основы праздничной культуры татарского народа.
- Воспитывать патриотические чувства.

**Показ игр**

Татарские народные игры:
"Перетяни канат".
"Не пролей воды".
"Положить колечко" -"Йөзек салыш",
"Разбей горшок".

**«Тюбитейка» (**Дети становятся в круг. Под национальную музыку они по очереди надевают тюбетейку на голову рядом стоящего ребенка. Музыка

прекращается, на ком остается тюбетейка тот выполняет задание: читает стихи, поет песни, танцует и т. д. на татарском языке).
***(Дети выходят под музыку передают тюбитейку, у кого остается тюбитейка тот рассказывает стих, поет песню).***

***-Молодцы! Хорошо поиграли. Вам понравилось?***

Традиционные соревнования сабантуя: - Бой мешками с сеном верхом на бревне. Цель – выбить противника «из седла».
- Бег в мешках. Только они такие узкие, что бег превращается в скачки.
- Игра «Разбей горшок»: участникам завязывают глаза, дают в руки длинную палку и велят ею разбить горшок.
Карабканье по очень высокому гладкому столбу. Наверху, естественно, ждет приз.
- Бег с ложкой во рту. Но ложка-то не пустая, в ней - сырое яичко, с которым необходимо прибежать первым к финишу.
- Скачки. Участники – юные наездники 10-15 лет. Интересный момент: награждается не только победитель, но и тот, кто пришел последним. Действительно – на празднике обиженных и грустных быть не должно!
- Конкурсы для девушек – кто быстрее и лучше нарежет лапшу, кто больше воды принесет.
И какой же праздник без угощения! **СЛАЙД 8.**Там и тут можно отведать шашлыка, плова домашней лапшы (лякшя) и традиционных татарских угощений: эчпочмак, бишбармак, чак-чак, балиш, пярямяча. После общего сабантуя на майдане веселье продолжается в домах - и обязательно приглашают гостей, ведь праздник без гостей у татар считается признаком необщительности.
Обряды татар при рождении ребенка Рождение ребенка сопровождалось целым рядом обязательных обрядов, имеющих как чисто ритуальное, так и практическое значение.

**Найти пары слов: татарско-русские**

Цель: назвать русские слова по-татарски.

Среда.

Образовательная деятельность в режимные моменты.

Исэнмесез!-Здравствуйте!

Тюбэтэй-Тюбитей

Жыр-песня

Халык-Народ

**Художественное творчество: Рисование.**

Тема: Украшение тюбетейки татарским национальным орнаментом. **СЛАЙД 9,10**

Цели: Учить рисовать цветок формообразующими движениями из дуг, сочетая цвета, располагать элементы татарского узора ритмично; закреплять знания о содержании татарского растительного орнамента, воспитывать интерес и любовь к татарскому народному орнаментальному искусству.

Задачи:
• Познакомить детей с татарским орнаментом. Развивать творческие способности детей, глазомер, художественный вкус.
• Воспитывать любовь к народному искусству.
• Научить, последовательно выполнять задание воспитателя.

**- Какие цвета в татарском орнаменте?**

1. Рассматривание образца.

2. Объяснение и показ способов и этапов работы.

3. Работа детей.

4. Анализ занятия.

Вопросы к занятию:

**- Люди каких национальностей живут в нашей стране?**
**- Что такое национальная одежда татар, чем она отличается от нашей одежды?**

**- Каким узором будем украшать?**

**- Какие элементы татарского узора вы знаете?**

**<u>Заключительная часть</u>:**

-Ребята, что нового вы узнали на **занятии**?-Какие новые слова узнали?
-Как называется любимый **татарами праздник**?
-Кто скажет, как называются **татарские головные уборы**?
-Калфак и тюбетейка.
- Ребята вы все хорошо поработали на уроке молодцы! Афарин! Сау булыгыз! До свидания.

Приложение:

1. Презентация к уроку.

2. Презентация проведенного урока.